ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясына үзгәреш кертү хакында» 22-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.Г. Хәбибуллин, А.А. Чубаров тарафыннан кертелгән «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясына үзгәреш кертү хакында» 22-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 28 ноябре
№ 106-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.Г. Хәбибуллин, А.А. Чубаров
тарафыннан кертелә

**Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 28 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясындагы 5 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 47 (часть I), № 79 (I өлеш), «2025 елның 1 гыйнварына» сүзләрен «2028 елның 1 гыйнварына» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә:

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

**«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында» 2015 елның 25 апрелендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын[1] гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 25 гыйнварындагы 35 номерлы карары нигезендә хокук саклау юнәлешендәге муниципаль хезмәткәрләр санын бүлү расланды.

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясына үзгәреш кертү хакында» закон проекты[2] белән Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясына, муниципаль хезмәтнең тиешле вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларга 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә катнашу керсә, муниципаль хезмәт вазыйфаларының өлкән һәм (яисә) кече төркемнәрен биләү өчен белем турында квалификация таләпләренә карата вакытлыча характердагы норманы озайту өлешендә үзгәреш кертү күздә тотыла.

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон белән һөнәри белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләре муниципаль хезмәт вазыйфалары классификациясе нигезендә Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнә торган муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен типлаштырылган квалификация таләпләре нигезендә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы[3] белән һөнәри белем дәрәҗәсе кирә торган типлаштырылган квалификация таләпләре билгеләнде. Шул ук вакытта белем дәрәҗәсенең иң түбәне булып эшчәнлекнең тиешле юнәлешенә туры килә торган урта һөнәри белем исәпләнә.

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының әлеге 42 статьясы вакытлыча характердагы нормага ия, аның нигезендә муниципаль хокукый актлар белән тәкъдим ителә торган квалификация таләпләренә карата гомуми кагыйдәдән чыгарма билгеләү мөмкинлеге каралды.

Хокук саклау юнәлешендәге муниципаль хезмәткәрләргә хокук бозуларны профилактикалау чараларын гамәлгә ашыруга һәм хокук бозуларны профилактикалау субъектлары белән хезмәттәшлек итүгә юнәлдерелгән берничә бурыч һәм вазыйфа, шул исәптән 2006 елның 19 декабрендәге 80-ТРЗ номерлы Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы буенча административ эш башкару хокукы, йөкләнгән.

Административ хокук бозулар турында федераль һәм региональ законнарда административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар өчен профиле яисә белем дәрәҗәсен билгеләү буенча нормалар юк.

---

[1] Алга таба – 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы
[2] Алга таба – закон проекты
[3] Алга таба – Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы

33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларының төп бурычы җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итүгә ярдәм итүдән гыйбарәт, ул муниципаль хезмәткәрләрне эчке эшләр органнарының рядовой һәм кече җитәкчелек составы вазыйфалары санынннан булган строй бүлекчәләре хезмәткәрләре белән берлектә җәмәгать тәртибен саклауда катнашуга җәлеп итү юлы белән гамәлгә ашырыла.

«Россия Федерациясе эчке эшләр органнарында хезмәт итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 30 ноябрендәге 342-ФЗ номерлы Федераль закон белән эчке эшләр органнарындагы вазыйфаларга карата квалификация таләпләре рядовой һәм кече җитәкчелек составы вазыйфалары өчен урта гомуми белем булуны күздә тота дип билгеләнгән.

Муниципаль хезмәтнең өлкән һәм кече төркемнәре вазыйфаларын биләү өчен таләпкә карата вакытлыча характердагы норманы озайту өлешендә үзгәрешләр кертү зур эш тәҗрибәсенә ия һәм җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итүне оештыру мәсьәләләрендә компетентлы булган иң тәҗрибәле кандидатларны, шул исәптән хокук саклау органнарының элеккеге хезмәткәрләре, беренче чиратта – полициянең строй бүлекчәләре (полициянең патруль-пост хезмәте, ведомстводан тыш сак, юл-патруль хезмәте) составыннан сайлап алу өчен кирәк. Кагыйдә буларак, элеккеге хезмәткәрләрнең мондый категориясе бары тик урта гомуми белемгә генә ия, бу исә хәзерге вакытта аларга муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылырга мөмкинлек бирми.

Татарстан Республикасында күпсанлы халыкара күләмдәге һәм бөтенроссия күләмендәге чаралар үткәрелә. Аларны әзерләү һәм уздыру чорында җәмәгать иминлеген тәэмин итү буенча күбрәк белгечләрне җәлеп итү зарурлыгы барлыкка килә. Шуңа бәйле рәвештә әлеге закон проекты белән Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясына үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

Законны гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.

**«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәртүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын финанс-икътисадый нигезләү**

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.